КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 октябрь г.Казань № 1230

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2001 ел, 30 июль, 503 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2001 ел, 30 июль, 503 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 604 нче, 2023 ел, 24 апрель, 515 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәне расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Коллегия составына Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, аның урынбасарлары, Министрлыкның һәм Министрлыкның ведомство буйсынуындагы оешмаларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары вәкилләре, галимнәр һәм белгечләр керә.»;

1.5 пунктта «министрлыклар, дәүләт комитеты, ведомстволар, җирле дәүләт идарәсе органнары, дәүләт предприятиеләре һәм башкалар» сүзләрен «республика

башкарма хакимият органнары, дәүләт һәм башка органнар» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта:

бишенче абзацта «предприятиеләрне үстерү» сүзләрен «оешмаларны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «республика максатчан программалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «предприятие һәм оешмаларның» сүзләрен «оешмаларының» сүзенә алмаштырырга;

уникенче абзацта «мелиоратив эшләр» сүзләрен «мелиоратив чаралар» сүзләренә алмаштырырга, «авыл хуҗалыгы предприятиеләре» сүзләрен «авыл хуҗалыгы оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

уналтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктта «кадрлар һәм кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләрен «оештыру эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.11 пунктта «кадрлар һәм кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләрен «оештыру эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.13 пунктта:

беренче абзацта «Кадрлар һәм кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләрен «Оештыру эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «, предприятие һәм башка оешмаларның» сүзләрен «һәм башка оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның икенче абзацында «кадрлар һәм кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләрен «оештыру эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин